Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының кырык беренче утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

19 ноябрь, 2024 ел № 114

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне[1] хәл итү буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башкарма комитеты:

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В.Поповская

[1]Исемлек киңәйтелергә мөмкин.